Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге составына керүче
Кече Укмас авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

19 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 30 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Кече Укмас авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан һәм махсус хәрби операциядә катнашучы һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 87 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 62 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 62 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Кече Укмас авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Кече Укмас авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан һәм махсус хәрби операциядә катнашучы һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы,23 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы: Ф.М.Динмөхәмәтов